ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.09.2019 с. Большие Меми 32

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п., Олы Меми авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү буенча бердәм инициатива күрсәтергә:

"2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 300 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:
- Гаврилов һәм Заречная урамнары буйлап Олы Меми авылы юлларына өлешчә вак таш җәю
- Заборная Поляна авылында су алу җайланмасын (каптажын) төзекләндерү:

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе ,
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
Башлыгы Г.А. Фомина